**"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге «муниципаль берәмлегенең ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«17» ноябрь 2019 ел № 2

**Гажданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге составына керүче Түбән Ушмы авылында Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы нигезендә», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст.», Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану һәм "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең Түбән Ушмы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Түбән Ушма авылына юл билгеләре сатып алу, урнаштыру;
- Түбән Ушма авылы буенча ясалма тигезсезлек урнаштыру;
- Түбән Ушма авылы буенча урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эш өчен түләү;
- Түбән Ушма авылы чишмәсенә капиталь ремонт
- су үткәрү торбасын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Түбән Ушма авылында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Түбән Ушма авылларында урам утлары объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырткычлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).
-Түбән Ушмы авылында юлларга вак таш җәеп ремонт ясау

« ӘЙЕ» «ЮК»

соравы буенча 2019 нчы елның 17 нчы ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 729 граждан кертелгән;
гражданнар җыенында катнашучы 435 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе " позициясе өчен»- барлыгы 428 кеше тавыш бирде;
"Юк" дип 7 тавыш
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Хафизовка авылында үткән гражданнар жыенын- уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең Түбән Ушмы авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең Түбән Ушмы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
- Түбән Ушма авылына юл билгеләре сатып алу, урнаштыру;
- Түбән Ушма авылы буенча ясалма тигезсезлек урнаштыру;
- Түбән Ушма авылы буенча урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эш өчен түләү;
- Түбән Ушма авылы чишмәсенә капиталь ремонт
- су үткәрү торбасын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Түбән Ушма авылында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Түбән Ушма авылларында урам утлары объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырткычлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).
-Түбән Ушмы авылында юлларга вак таш җәеп ремонт ясау

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы авыл җирлеге
Советы рәисе Р.М. Ганиев